| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**05.02.2020** **г.Казань** **№ 15/2-пр**

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында, БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 29 мартындагы 60/2-пр номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 26.04.2017 № 92/2-пр, 27.09.2017 № 219/2-пр, 21.02.2018 № 39/2-пр, 10.07.2018 № 158/2-пр, 28.02.2019 № 38/2-пр, 10.06.2019 № 121/2-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - 60/2-пр номерлы Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

60/2-пр номерлы Боерык белән расланган «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программасында (алга таба - Программа):

«Программаны эшләү турында карар кабул итү датасы (аны раслау датасы, тиешле норматив актның исеме һәм номеры) Программаның Паспорты» графасында һәм алга таба текст буенча «2013-2021 елларга» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда «2013-2022 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

60/2-пр номерлы Боерык белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта:

3.1.18 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.18. Тиешенчә таныклланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яисә) Россия Федерациясе хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләрне;»;

3.1.17 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

3.1.19 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

3.1.21 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.21. Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәтенә КДН 1151111 формасы буенча соңгы хисап датасына иминият кертемнәре буенча исәп-хисап;».

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына (22.05.2017 № 117/2-пр, 25.10.2017 № 240/2-пр, 13.03.2018 № 49/2-пр, 09.04.2018 № 79/2-пр, 26.02.2019 № 36/2-пр, 10.06.2019 № 123/2-пр) боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - 66/2-пр номерлы Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

66/2-пр номерлы Боерык белән расланган «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында:

«Программаны эшләү турында карар кабул итү датасы (аны раслау датасы, тиешле норматив актның исеме һәм номеры)», «Программа чараларына характеристика» графаларында һәм алга таба текст буенча «2013-2021 елларга» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда «2013-2022 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

66/2-пр номерлы Боерык белән расланган Крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыруга һәм үстерүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта:

3.1.3 пунктчаның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.1.3 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) тиешенчә таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яисә) Россия Федерациясе хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы, авыл хуҗалыгында авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча кимендә 3 ел эш стажы булуын раслый торган белешмәләрне.»;

3.1.19 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.19. Тиешенчә таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яисә) Россия Федерациясе хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләрне.»;

3.1.21 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр М.А. Җәббаров